2023 елда «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы»муниципаль берәмлегендә үзара салым кертү турында гражданнар җыены карары

2022 елның 9 декабре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге карар итте:

1. Ташламалы категорияләрдән тыш, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан (беренче, икенче төркем инвалидлар, балачактан инвалидлар, тыл хезмәтчәннәре, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар һәм укучылар) 2023 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә; күп балалы гаиләләр (5 һәм аннан да күбрәк балалар).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Томбай урамы, коммуналь урамы, Чирков урамы буенча коеларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән су анализы үткәрү (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Бу карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерү:

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кама Тамагы ш. т. б., Совет ур., 11;

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кама Тамагы ш. т. б., К. Маркс ур., 105 китапханә бинасы,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Җыенда рәислек итүче, "Кама Тамагы шәһәр

тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге

башлыгы урынбасары Р. Х. Дәүләтшин